**ТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«25» октябрь 2023 ел № 340

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 январендагы 1-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 3 февралендәге 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законнары, «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен расларга.

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 5 августындагы 40 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru)

һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарм комитет Җитәкчесе А.Г. Даутов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 25 октябрь 340 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен билгели (алга таба – административ регламент, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган).

1.2. Административ регламентлар муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар тарафыннан эшләнә һәм раслана.

1.3. Административ регламентлар федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Законнары, Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү турында белешмәләр «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – хезмәтләр реестры) кертелгәннән соң (ул булганда), муниципаль хезмәт күрсәтүнең бердәм стандарты нигезендә эшләнә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүматларны хезмәтләр реестрына кертү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне (функцияләрне гамәлгә ашыруны) электрон формада тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системалары турында» 2011 елның 24 октябрендәге 861 номерлы карарына һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан раслана торган муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре нигезендә башкарыла.

Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүче органның конкрет вәкаләтләрен билгеләүче норматив хокукый акт мондый вәкаләтләрне гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче аерым норматив хокукый акт кабул итүне күздә тотса, әлеге норматив хокукый актны эшләү белән берләттән тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты расланырга тиеш. Шул ук вакытта муниципаль норматив хокукый акт белән расланган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруның күрсәтелгән тәртибе белән әлеге Тәртип нигезендә административ регламентның көйләү предметына кергән мәсьәләләр көйләнми.

Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү муниципаль учреждение тарафыннан тәэмин ителә икән, административ регламент Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең мондый учреждениене гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы (алга таба – җирле үзидарә органы) тарафыннан эшләнә һәм раслана.

Әлеге пунктның беренче, өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән административ регламентлар муниципаль хезмәтне гамәлгә ашыру вәкаләтләре барлыкка килгән көннән алып 60 календарь көнен тәшкил итүче срок дәвамында эшләнә һәм раслана дип билгеләргә.

1.4. Административ регламентлар проектларын эшләү, килештерү, экспертиза үткәрү һәм раслау муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар һәм административ регламент проектына экспертиза үткәрүгә вәкаләтле орган тарафыннан, хезмәтләр реестрының программа-техник чараларын кулланып, «Дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен үз көчләрен югалткан дип тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 20 июлендәге 1228 номерлы карары һәм әлеге Тәртип нигезендә башкарыла.

1.5. Административ регламентларны эшләү түбәндәге этапларны үз эченә ала:

а) муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар тарафыннан хезмәтләр реестрына муниципаль хезмәт турында, шул исәптән аны күрсәткәндә административ гамәлләрнең логик яктан аерымланган эзлеклелеге турында мәгълүмат кертү (алга таба – административ процедуралар);

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 12 статьясы 3 өлешендә каралган таләпләр нигезендә машина белән укыла торган төргә үзгәртү;

в) әлеге Тәртипнең II бүлеге белән билгеләнгән административ регламентларның структурасына һәм эчтәлегенә таләпләр нигезендә әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлардан административ регламентны автомат рәвештә формалаштыру.

1.6. Әлеге Тәртипнең 1.5 пункты «а» пунктчасында күрсәтелгән муниципаль хезмәт турында мәгълүмат түбәндәгеләрне тасвирлау өчен җитәрлек булырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтүнең бер нәтиҗәсе өчен мөрәҗәгать иткән һәм уртак билгеләр белән берләштерелгән барлык категория гариза бирүчеләрне;

әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән һәр категория гариза бирүчеләр өчен уникаль булган административ процедураларны гамәлгә ашыру вакыты һәм тәртибе, шул исәптән административ процедуралар башлау өчен нигезләр, карарлар кабул итү критерийлары, административ процедуралар нәтиҗәләре һәм аларны фиксацияләү ысуллары, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат составы турында мәгълүматлар, мондый документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул итү критерийлары, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү варианты).

Әлеге Тәртипнең 1.5 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә машина белән укыла торган төргә үзгәртелгән муниципаль хезмәт күрсәтүгә бирелгән мәгълүматлар, тиешле административ регламент үз көченә кергәннән соң, административ регламентны автоматлаштырылган рәвештә үтәү өчен кулланылырга мөмкин.

1.7. Административ регламентларны эшләгәндә, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерүне (сыйфатын күтәрүне), шул исәптән муниципаль хезмәтләрне алданрак (проактив) режимда күрсәтү мөмкинлеген, муниципаль хезмәтләр алуның күпканаллылыгын һәм экстерриториальлеген, муниципаль хезмәт күрсәтүнең барлык вариантларын тасвирлауны, артык административ процедураларны бетерүне һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын күздә тоткан идарә итү процессларына, шулай ук муниципаль хезмәт алу өчен таләп ителә торган документларга һәм (яки) мәгълүматка реинжиниринг, муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең реестр моделен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең Федераль законда каралган башка принципларын кертү үткәрәләр.

1.8. Административ регламентларның исемнәре муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар тарафыннан тиешле муниципаль хезмәт каралган норматив хокукый актның формулировкасын исәпкә алып билгеләнә.

## II. Административ регламентларның структурасына һәм эчтәлегенә таләпләр

2.1. Административ регламентка түбәндәге бүлекләр кертелә:

а) гомуми нигезләмәләр;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты;

в) административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш срогы;

г) административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары;

д) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба – күпфункцияле үзәк), Федераль законның 16 статьясы 11 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазифаи затлары, муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирүнең судка кадәрге (судтан тыш) тәртибе.

2.2. «Гомуми нигезләмәләр» бүлегенә түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) административ регламентның көйләү предметы;

б) гариза бирүчеләр даирәсе;

в) гариза бирүчегә муниципаль муниципаль хезмәтне күрсәтүче орган үткәргән анкеталаштыру нәтиҗәсендә (алга таба – профильләштерү) билгеләнгән гариза бирүченең тиешле билгеләренә туры килгән хезмәт күрсәтү варианты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук гариза бирүче сорап мөрәҗәгать иткән нәтиҗә күрсәтү турында таләп.

2.3. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлеге түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) муниципаль хезмәтнең исеме;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган исеме;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе;
г) муниципаль хезмәт күрсәтү срогы;
д) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр;
е) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге;
ж) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;
з) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге;
и) муниципаль хезмәт күрсәтү вакытында гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары;
к) гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта торуның максималь вакыты;
л) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы;
м) муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр;
н) муниципаль хезмәт күрсәтүнең уңайлылыгы һәм сыйфаты күрсәткечләре;
о) муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:
күпфункцияле үзәкләрдә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен һәм электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алу;
Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә муниципаль хезмәт хакында мәгълүмат бирү турында.
2.4. «Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган исеме» бүлекчәсе түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:
а) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның тулы исеме;
б) күпфункцияле үзәк тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле запросны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге (мөмкин түгеллеге) (әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос күпфункцияле үзәккә тапшырылырга мөмкин булса).
2.5. «Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе» бүлекчәсе түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:
а) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең (нәтиҗәләренең) исеме;
б) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтү турында карарны үз эченә алган документның исеме һәм реквизитлар составы;
в) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында реестр язмасы составы, шулай ук мондый реестр язмасы урнаштырылган мәгълүмати ресурсның исеме (әгәр муниципаль хезмәтләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләрен бирү нәтиҗәсе реестр язмасы булса);
г) мөрәҗәгать итүченең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу факты теркәлгән мәгълүмат системасының исеме;
д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу ысулы.
2.6. Әлеге Тәртипнең 2.5 пунктында күрсәтелгән нигезләмәләр муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәр варианты өчен административ регламентның мондый вариантларның тасвирламаларын үз эченә алган бүлекчәләрендә китерелә.

2.7. «Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы» бүлекчәсе муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш, ул муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле запросны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматны теркәгән көннән исәпләнә:

муниципаль хезмәт күрсәтүче органда, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүче органга почта аша җибәрелгән очракта;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмат системасында (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы);

күпфункцияле үзәктә, әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәктә тапшырылган булса.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәр варианты өчен муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы административ регламентның мондый вариантларның тасвирламаларын үз эченә алган бүлекчәләрендә китерелә.

2.8. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен хокукый нигезләр» бүлекчәсе муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтында, шулай ук Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылуы турында мәгълүматны, муниципаль хезмәт күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге, муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

2.9. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге» бүлекчәсе муниципаль хезмәт күрсәтү өчен закон чыгару яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның, гариза бирүче үзе тәкъдим итәргә тиеш булган документларга һәм мәгълүматка һәм гариза бирүче үз инициативасы буенча тәкъдим итәргә хокуклы булган (чөнки алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиеш) документларга бүленеп, тулы исемлеген, шулай ук түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос бирү составы һәм ысуллары, ул үз эченә алырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтүче органның тулы исеме;

Россия Федерациясе законнарында каралган документларда гариза бирүчене идентификацияләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

Россия Федерациясе законнарында каралган документларда гариза бирүче вәкилен идентификацияләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматлар;

муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле өстәмә мәгълүмат;

запроска теркәлә торган документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеге;

норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм гариза бирүчеләр өчен мәҗбүри тапшырырга тиеш булган документларның (документлар категорияләренең) исеме, шулай ук күрсәтелгән документларны (документлар категорияләрен) тапшыру таләпләре;

норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (документлар категорияләре) һәм гариза бирүчеләр тарафыннан үз инициативалары буенча тәкъдим ителә торган документлар (документлар категорияләре) исеме.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле рәвештә бирелә торган запрос һәм башка документлар формалары административ регламентка кушымта буларак китерелә, күрсәтелгән документлар формалары Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте яки Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән билгеләнгән очраклардан тыш.

Әлеге пунктның сигезенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән документларның тулы исемлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәр варианты өчен административ регламентның мондый вариантларның тасвирламаларын үз эченә алган бүлекчәләрендә китерелә.

2.10. «Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге» бүлекчәсе мондый нигезләрнең тулы исемлеге турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәр варианты өчен нигезләрнең тулы исемлеге мондый вариантларның тасвирламаларын үз эченә алган административ регламент бүлекчәләрендә китерелә. Мондый нигезләр булмаган очракта, административ регламент текстында аларның булмавын турыдан-туры күрсәтергә кирәк.

2.11. «Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге» бүлекчәсе түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә алырга тиеш:

муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләрнең тулы исемлеге;

муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән һәр нигез өчен муниципаль хезмәт күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү критерийлары һәм тиешле административ процедуралар тасвирламасы составына кертелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору турында карар кабул итү критерийлары карала.

Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында каралган нигезләрнең тулы исемлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәр варианты өчен административ регламентның мондый вариантларның тасвирламаларын үз эченә алган бүлекчәләрендә китерелә. Мондый нигезләр булмаган очракта, административ регламент текстында аларның булмавын турыдан-туры күрсәтергә кирәк.

2.12. «Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары» бүлегенә түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү күләме турында мәгълүмат урнаштыру турында белешмәләр;

б) федераль законнарда, алар нигезендә кабул ителә торган башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралган очракларда аны алу тәртибе һәм ысуллары.

2.13. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган биналарга таләпләр» бүлегенә мондый биналар, шул исәптән көтү залы, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру өчен урыннар, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеге белән мәгълүмати стендлар, шулай ук әлеге объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнары нигезендә инвалидлар өчен мөмкинлеген тәэмин итү таләпләре керә.

2.14. «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат һәм уңайлылык күрсәткечләре» бүлегенә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат һәм уңайлылык күрсәткечләре исемлеге кертелә, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон формаларыннан файдалану мөмкинлеге, муниципаль хезмәт алу өчен электрон формада запрос һәм документларбирү мөмкинлеге, муниципаль хезмәтне вакытында күрсәтү (муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу булмау), муниципаль хезмәт күрсәтү вариантына туры китереп муниципаль хезмәт күрсәтү, муниципаль хезмәт алу өчен кирәкле электрон түләүләр рәвешендә башкару коралларының булуы, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат бирү, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу уңайлылыгы.

2.15. «Муниципаль хезмәт күрсәтүгә башка таләпләр» бүлегенә түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләме, түләү күләме Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очракларда;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге.

2.16. «Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш срогы» бүлеге административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү тәртибенә, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләренә, күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләренә таләпләрне билгели һәм түбәндәге бүлекчәләрне үз эченә алырга тиеш:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда һәм төзелгән реестр язмаларындагы хаталарны төзәтү өчен кирәкле муниципаль хезмәт күрсәтү вариантлары исемлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документның дубликатын

бирү өчен кирәкле муниципаль хезмәт күрсәтү вариантларын, шул исәптән мондый дубликат бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеген дә үз эченә ала, ә шулай ук гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын карамыйча (кирәк булганда) калдыру тәртибе;

б) гариза бирүчене профильләштерүнең административ процедурасын тасвирлау;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү вариантларының тасвирламасын үз эченә алган бүлекчәләр.

2.17. Мөрәҗәгать итүчене профильләштерүнең административ процедурасы тасвирламасына мөрәҗәгать итүчегә кирәкле муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын билгеләү һәм күрсәтү ысуллары һәм тәртибе кертелә.

Административ регламентка кушымтада гариза бирүчеләрнең категорияләре берләштерелгән гомуми билгеләр исемлеге, шулай ук гариза бирүчеләрнең билгеләре комбинациясе китерелә, аларның һәрберсе муниципаль хезмәт күрсәтүнең бер вариантына туры килә.

2.18. Муниципаль хезмәт күрсәтү вариантларының тасвирламасын үз эченә алган бүлекчәләр әлеге Тәртипнең 2.16 пункты «а» пунктчасында каралган хезмәт күрсәтү вариантлары саны буенча формалаштырыла һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен, муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ процедуралары исемлеген һәм тасвирламасын, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү варианты нигезендәә муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогын үз эченә алырга тиеш.

2.19. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүнең административ процедурасы тасвирламасына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) запрос составы һәм муниципаль хезмәт күрсәтү варианты нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яки) мәгълүмат исемлеге, шулай ук мондый запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүмат бирү ысуллары;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәр запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүмат бирү ысулы өчен гариза бирүченең (гариза бирүче вәкиленең) шәхесен билгеләү ысуллары;

в) гариза бирүче вәкиле тарафыннан запрос бирү мөмкинлеге булу ( булмау);

г) сорауны һәм документларны һәм (яки) мәгълүматны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен нигезләр, ә мондый нигезләр булмаган очракта, аларның булмавын күрсәтү;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос кабул итүдә катнашучы җирле үзидарә органнары, шул исәптән күпфункцияле үзәккә  запрос бирү мөмкинлеге (мондый мөмкинлек булганда) турында мәгълүмат;

е) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган яки күпфункцияле үзәк тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүматны гариза бирүче сайлавы буенча, гариза бирүченең яшәү урынына яки булу урынына (физик затлар өчен, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр өчен) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) карамастан кабул итү мөмкинлеге (мөмкин түгеллеге);

ж) муниципаль хезмәт күрсәтүче органда яки күпфункцияле үзәктә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле запрос һәм документлар һәм (яки) мәгълүматны теркәү срогы.

2.20. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекнең административ процедурасы тасвирламасына муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле ведомствоара запрослар исемлеге кертелә, ул үз эченә алырга тиеш:

ведомствоара запрос җибәрелә торган федераль башкарма хакимият органы, республика башкарма хакимияте органы исеме һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле мәгълүматлар җирле үзидарә органнары карамагында булуы турында мәгълүмат;

ведомствоара запроста җибәрелә торган мәгълүмат;

куллану максатын күрсәтеп, ведомствоара запроста соралган мәгълүматлар;

ведомствоара запрос өчен нигез, аны җибәрү срогы;

ведомствоара запрос нәтиҗәсе муниципаль хезмәт күрсәтүче органга керергә тиешле срок.

2.21. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасы тасвирламасына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр исемлеге, ә мондый нигезләр булмаган очракта, аларның булмавын күрсәтү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торганда гамәлгә ашырыла торган административ гамәлләрнең составы һәм эчтәлеге;

в) муниципаль хезмәт күрсәтүне яңадан башлау өчен нигезләр исемлеге.

2.22. Муниципаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итүнең административ процедурасы тасвирламасына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү критерийлары;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту турында) турында карар кабул итү срогы, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган карар кабул итү өчен кирәкле барлык мәгълүматларны алган датадан исәпләнә.

2.23. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтүнең административ процедурасы тасвирламасына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен күрсәтү ысуллары;

б) мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү турында карар кабул ителгән көннән исәпләнә торган муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү срогы;

е) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган яки күпфункцияле үзәк тарафыннан муниципаль хезмәт нәтиҗәсен гариза бирүче сайлавы буенча, гариза бирүченең яшәү урынына яки булу урынына (физик затлар өчен, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр өчен) яки урнашу урынына (юридик затлар өчен) карамастан кабул итү мөмкинлеге (мөмкин түгеллеге);

2.24. Мөрәҗәгать итүчедән өстәмә мәгълүмат алуның административ процедурасы тасвирламасына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү процессында гариза бирүчедән өстәмә документлар һәм (яки) мәгълүмат алу өчен нигезләр;

б) мондый документлар һәм (яки) мәгълүмат алу өчен кирәкле срок;

в) гариза бирүчедән өстәмә мәгълүмат алу кирәк булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен кирәклекне (кирәк булмауны) күрсәтү;

г) административ процедурада катнашучы җирле үзидарә органнары исемлеге, әгәр алар билгеле булса (кирәк булганда).

2.25. Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү варианты муниципаль хезмәтне алданрак (проактив) режимда күрсәтүне күздә тота икән, муниципаль хезмәт күрсәтү вариантының тасвирламасын үз эченә алган бүлекчә составына түбәндәге нигезләмәләр кертелә:

а) мөрәҗәгать итүче тарафыннан әлеге муниципаль хезмәтне алданрак (проактив) режимда күрсәтү турында алдан гариза бирү кирәклегенә күрсәтмә яки яки гариза бирүче тарафыннан әлеге муниципаль хезмәт күрсәтү турында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан Федераль законның 73 статьясы 1 өлеше 1 пункты нигезендә чаралар үткәрелгәннән соң бирү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның мәгълүмат системасына кергән юридик факт турында мәгълүматлар мөрәҗәгать итүчегә әлеге муниципаль хезмәтне алданрак (проактив) режимда күрсәтү өчен нигез булып тора;

в) әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар керергә тиеш булган мәгълүмат системасының, шулай ук әлеге мәгълүмат керергә тиеш булган муниципаль хезмәт күрсәтүче орган мәгълүмат системасының исеме;

г) әлеге органның мәгълүмат системасына әлеге пунктның «б» пунктчасында күрсәтелгән мәгълүматлар кергәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлеш срогы.

2.26. «Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары» бүлеге түбәндәге бүлекчәләрдән тора:

а) җаваплы вазыйфаи затларның административ регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларны үтәвенә агымдагы контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итү тәртибе;

б) муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү тәртибе һәм вакытлычалыгы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тәртибе һәм формалары;

в) муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителгән (гамәлгә ашырылган) карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмау) өчен муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазифаи затларының җаваплылыгы;

г) муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибенә һәм формаларына, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан, таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр.

2.27. «Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, күпфункцияле үзәкнең, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы 11 өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазифаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе» бүлеге гариза бирүчеләргә

судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирү ысулларын, шулай ук гариза бирүчеләрнең шикаять бирү формалары һәм ысулларын үз эченә алырга тиеш.

## III. Административ регламентларны килештерү һәм раслау тәртибе

3.1. Административ регламент проекты муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган тарафыннан машина белән укыла торган форматта электрон рәвештә хезмәтләр реестрында формалаштырыла.

3.2. Хезмәтләр реестрының мәгълүмати ресурсын алып бару буенча вәкаләтле орган административ регламент проектын эшләүдә, килештерүдә һәм раслауда катнашу өчен керү мөмкинлеген түбәндәгеләргә тәэмин итә:

а) муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнарга;

б) башка җирле үзидарә органнарына, әгәр муниципаль норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелгән органнар тарафыннан административ регламент проектын мондый органнар компетенциясенә кертелгән өлештә килештерү таләп ителсә;

в) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган белән норматив хокукый актлар проектларына хокукый һәм (яки) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү турында килешү нигезендә (алга таба – экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган, килешү) административ регламент проектына хокукый һәм (яки) коррупциягә каршы экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы органга;

г) административ регламент проектына экспертиза үткәрүгә вәкаләтле органга.

3.3. Муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, әлеге Тәртипнең 3.2 пункты «б» пунктчасында күрсәтелгән җирле үзидарә органнары, экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган (алга таба – килештерүдә катнашучы органнар) административ регламент проектын әзерләгәннән соң формалаштырыла торган административ регламент проектының килештерү кәгазенә (алга таба – килештерү кәгазе) автомат рәвештә кертелә.

3.4. Административ регламент проекты килештерүдә катнашучы органнар тарафыннан, мондый орган компетенциясенә кертелгән өлештә, ул хезмәтләр реестрында килештерүгә кергән датадан алып биш эш көненнән артмаган срокта, ә экспертиза үткәрүче орган тарафыннан килештерүдә билгеләнгән срокта карала.

3.5. Килештерү процедурасы башлану белән бер үк вакытта коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү максатында, административ регламент проекты автомат режимда «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтында хезмәтләр реестры белән интеграцияләү юлы белән урнаштырыла.

3.6. Административ регламентлар проектларына бәйсез экспертиза «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларына һәм муниципаль норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге советының 2010 елның 22 августындагы 56 номерлы карары нигезендә уздырыла.

3.7. Административ регламент проектын килештерүдә катнашучы органның карау нәтиҗәсе булып мондый органның административ регламент проектын килештерү яки килештермәү турында карар кабул итүе тора.

Административ регламент проектын килештерү турында карар кабул иткәндә, килештерүдә катнашучы орган килештреү битендә проектны килештерү турында билге куя.

Административ регламент проектын килештермәү турында карар кабул иткәндә, килештерүдә катнашучы орган хезмәтләр реестрында формалаштырыла торган һәм килештерү кәгазе кушымтасы булган каршылыклар беркетмәсе проектына булган искәрмәләрне кертә.

3.8. Килештерүдә катнашучы барлык органнар тарафыннан административ регламент проектын каралганнан соң, шулай ук каршылыклар беркетмәләре (булган очракта) һәм бәйсез коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кергәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган килгән искәрмәләрне карый.

Административ регламент проектын эшләп бетергәндә бәйсез коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәмләрне исәпкә алу мөмкинлеге турында карар «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителә.

Килештерүдә катнашучы органнар тарафыннан бирелгән искәрмәләр белән килешү очрагында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, биш эш көненнән артмаган срокта, алынган искәрмәләрне исәпкә алып, әлеге Тәртипнең 1.5 пункты «а» пунктчасында күрсәтелгән муниципаль хезмәт турында мәгълүматларга үзгәрешләр кертә һәм аларны машина белән укыла торган төргә үзгәрткәннән соң, шулай ук административ регламент проектын формалаштырганнан соң, күрсәтелгән килештерүдә катнашучы органнарга кабат килештерү өчен административ регламент проектын җибәрә.

Искәрмәләргә каршылыклар булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган каршылыклар беркетмәсе проектына килештерүдә катнашучы органның (килештерүдә катнашучы органнарның) искәрмәләренә каршылыклар кертү һәм мондый беркетмәне күрсәтелгән органга (күрсәтелгән органнарга) җибәрү юлы белән фикер каршылыкларын җайга салу процедурасын башлап җибәрергә хокуклы.

3.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тәкъдим иткән каршылыклар белән килешү очрагында, килештерүдә катнашучы орган (килештерүдә катнашучы органнар) каршылыклар беркетмәсе проектында фикер каршылыкларын җайга салу турында билге куя (куялар), каршылыклар беркетмәсен имзалый (имзалыйлар) һәм, килештерү кәгазендә тиешле билге куеп, административ регламент проектын килештерә (килештерәләр).

Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тәкъдим иткән каршылыклар белән килешмәү очрагында, килештерүдә катнашучы орган (килештерүдә катнашучы органнар) каршылыклар беркетмәсе проектында административ регламент проектын килештерүдән кабат баш тарту турында билге куя (куялар) һәм каршылыклар беркетмәсен имзалый (имзалыйлар).

3.10. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, килештерүдә катнашучы орган (килештерүдә катнашучы органнар) административ регламент проектын килештерүдән кабат баш тартканнан соң, административ регламент проектына үзгәрешләр кертү һәм аны килештерүдә катнашучы барлык органнарга кабат килештерүгә җибәрү турында карар кабул итә.

3.11. Административ регламент проекты буенча фикер каршылыклары Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән расланган Эш кагазьләрен алып бару буенча инструкциядә каралган тәртиптә хәл ителә (алга таба – Эш кәгазьләрен алып бару буенча инструкция).

3.12. Административ регламент проектын килештерүдә катнашучы барлык органнар белән килештергәннән соң яки административ регламент проекты буенча фикер каршылыкларын хәл иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган административ регламент проектын әлеге Тәртипнең IV бүлеген нигезендә экспертизага җибәрә.

3.13. Административ регламентны раслау экспертиза үткәрүче орган экспертизасының уңай бәяләмәсен алганнан соң яки экспертиза үткәрүче орган экспертизасы нәтиҗәләре буенча фикер каршылыкларын җайга салганнан соң, биш эш көне эчендә муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән хезмәт күрсәтүләр реестрында электрон документка кул кую юлы белән башкарыла.

3.14. Административ регламентка үзгәрешләр кертү өчен нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган административ регламентны үз көчен югалткан дип тану һәм әлеге Тәртип нигезендә яңа административ регламент кабул итү турында муниципаль норматив хокукый актны эшли һәм хезмәтләр реестрында раслый.

## IV. Административ регламентлар проектларына экспертиза үткәрү

4.1. Административ регламентлар проектларына экспертиза хезмәтләр реестрында экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган тарафыннан үткәрелә.

4.2. Экспертизаның предметы булып тора:

а) административ регламентлар проектларының әлеге Тәртипнең 1.3 һәм 1.7 пунктлары таләпләренә туры килүе;

б) карар кабул итү критерийларының әлеге Тәртипнең 2.11 пункты дүртенче абзацында каралган таләпләргә туры килүе;

в) проектта гариза бирүчеләрнең ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга мөмкин булган документларны һәм (яки) мәгълүматны мәҗбүри бирү турында таләпләр булмау.

4.3. Административ регламент проектын карау нәтиҗәләре буенча экспертиза үткәрүче орган 10 эш көне эчендә административ регламент проектына уңай бәяләмә бирү яки административ регламент проектына тискәре бәяләмә бирү турында карар кабул итә.

4.4. Административ регламент проектына уңай бәяләмә бирү турында карар кабул иткәндә, экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган килештерү кәгазенә тиешле билге куя.

4.5. Административ регламент проектына тискәре бәяләмә бирү турында карар кабул иткәндә, экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган килештерү битендә тиешле билге куя һәм каршылыклар беркетмәсенә искәрмәләр кертә.

4.6. Экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган бәяләмәсендә административ регламент проектына искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган мондый искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алуны тәэмин итә.

Фикер каршылыклары булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган каршылыклар беркетмәсенә экспертиза үткәрүче органның искәрмәләренә каршылык кертә.

4.7. Экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан тәкъдим ителгән каршылыкларны, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан мондый каршылыкларны каршылыклар беркетмәсенә керткән датадан биш эш көненнән дә артмаган срокта карый.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның каршылыклары белән килешкән очракта, экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган каршылыклар беркетмәсе проектында фикер каршылыкларын җайга салу турында билге куя, каршылыклар беркетмәсен имзалый һәм, килештерү битендә тиешле билге куеп, административ регламент проектын килештерә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның каршылыклары белән килешмәү очрагында, экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган каршылыклар беркетмәсенә тиешле билге куя.

4.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган һәм экспертиза үткәрүне гамәлгә ашыручы орган арасында административ регламент проекты буенча фикер каршылыклары Эш кагәзьләрен алып бару буенча инструкциядә каралган тәртиптә хәл ителә.